ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е　　　　К А Р А Р

2021 елның 21 декабре　　　　№14

Лениногорск муниципаль районы «Лениногорск шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районы» Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга пассажирлар йөртүне оештыру һәм җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү буенча чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 04 мартындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы «Лениногорск шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга пассажирлар йөртүне оештыру һәм җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү буенча чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 04 мартындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмә кертергә:

Карарның преамбуласында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең от 06.09.2016 № 887 ««Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр бирүдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары белән» сүзләрен - төшереп калдырырга;

Алда күрсәтелгән карар белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга пассажирлар йөртүне оештыру һәм җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү буенча чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү хакындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәи өстәмәләр кертергә:

2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2 абзац белән тулыландырырга:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба - бердәм порталда) бюджет турында карар проектын (бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар проектын) формалаштырганда Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба-бердәм порталда) мәгълүмат урнаштырырга.»;

2.2 пунктта 3 һәм 6 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы - юридик затлар үзгәртеп кору процессында (сайлап алуда катнашучы юридик затка кушылу формасында үзгәртеп корудан тыш), ликвидацияләнү, аларга карата банкротлык проөедурасы кертелмәгән, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучылар - индивидуаль эшкуар буларак (мондый таләпләр хокукый актта каралган очракта) эшчәнлекне туктатырга тиеш түгел;

субсидия алучы чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булган чит ил юридик затларының катнашуы өлеше Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимын һәм (яисә) финанс операцияләрен (офшор зоналар) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләт яисә территорияләр исемлегенә кертелгән чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында, тулаем алганда, 50 процентан артык;»;

түбәндәге эчтәлектәге 7 абзац белән тулыландырырга:

«дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, шәхси башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридик зат булып торучы субсидия алучының баш бухгалтеры турында, индивидуаль эшкуар турында һәм субсидия алучы булып торучы товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик зат турында мәгълүматлар юк (мондый таләпләр хокукый акт белән каралган очракта);

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Субсидияләрне күчерү тәртипнең 2.7 пунктында каралган документларны карау нәтиҗәләре буенча бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче тарафыннан гамәлгә ашырыла. Субсидияләрне күчерү срогы - бәяләмә кабул ителгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Субсидияләр Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучыларга ачык булган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерелә;

Субсидия алучы мәгълүмат бирә:

субсидия бирелә торган чыгымнар (алынмаган керемнәр) юнәлешләре турында;

фактта җитештерелгән чыгымнарны (алынмаган керемнәр) раслый торган документлар исемлеге турында, шулай ук кирәк булганда, мондый документларга карата таләпләр турында;

Килешү муниципаль берәмлекнең казна учреждениесе тарафыннан түләүсез (өлешчә түләүле) нигездә, шул исәптән җайга салынулы бәяләр (тарифлар) буенча, Лениногорск шәһәр суды карары белән билгеләнгән очракларда, физик затларга хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы субсидия алучы белән килешү (хокукый акт белән мондый килешү төзү каралган очракта) төзелгән очракта.».

2.Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорскские вести» газетасында бастырырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Сытдиков

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72